**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III нче чакырылыш)**

егерме тугызынчы утырыш
**КАРАРЫ**

21 август 2019 ел **№ 188** Теләче авылы

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2012 елнын 12 апрелендә кабул ителгән 97 нче номерлы «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү тәртибе турында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче районы прокуратурасының 13 июнь 2019 ел, № 02-01-23-2019 номерлы таләбен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар кылды:**

**1 Статья.**

«Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2012 елның 12 апрелендәге 97 номерлы Теләче муниципаль районы Советы карарына (2018елның 21 декабрендәге 152 номерлы, 2019 елның 28 мартындагы 170 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен бирү турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) II бүлекчәдә:

а) 27 пунктның беренче абзацында «29 пунктында» сүзләрен «33 пунктында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 Статья.**

Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф. Зарипов